МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

06.12.2021 г.Казань № 899

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 20 декабрендә 8635 номеры белән теркәлде

2022 елда вакытлыча эшкә урнаштырган чорда балигъ булмаганнарга һәм эшсез гражданнарга матди ярдәм күләмнәре турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2025 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 9 августындагы 553 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. 2022 елга түбәндәгечә матди ярдәм күләмнәрен билгеләргә:

14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру чорына бер кешегә аена 2250 сум күләмендә;

түләүле җәмәгать эшләрендә катнаша торган эшсез гражданнарны, эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру чорында бер кешегә аена 2250 сумга күләмендә;

урта һөнәри белеме яки югары белеме булган һәм белем яки квалификация турында документ тапшырылган датадан башлап ел дәвамында эш эзләгән 18 яшьтән 25 яшькәчә эшсез гражданнар өчен – аларны вакытлыча эшкә урнаштыру чорына бер кешегә 4500 сум күләмендә;

гомуми белем бирү оешмаларын һәм югары белем бирү оешмаларын тәмамлаучылар исәбендәге эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру чорына бер кешегә аена 4500 сум күләмендә.

2. Әлеге боерык 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп тору буенча министр урынбасары К.А. Таҗетдинованы җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Э.Ә.Зарипова